УДК 78

*А.Р. Салихова*

# СОЛТАН ГАБӘШИ: СӘНГАТЬКӘ БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

Творческая личность Султана Габаши сыграла важную роль в становлении татарского музыкального и театрального искусства. Его деятельность была многогранна: он проявил себя как исполнитель, композитор, дирижер, фольклорист, педагог и общественный деятель. Султан Габаши стал одним из авторов первых татарских опер «Сания» и «Эшче». Научное осмысление богатого музыкального наследия Султана Габаши представляет большой интерес.

**Ключевые слова:** Султан Габаши, композитор, театр, музыка, фольклор, опера.

The creative personality of Sultan Gabashi played an important role in the formation of the Tatar musical and theatrical art. His work was multifaceted: he showed himself as a performer, composer, conductor, folklorist, teacher and public figure. Sultan Gabashi became one of the authors of the first Tatar operas «Sania» and «Eshche». Scientific understanding of the rich musical heritage of Sultan Gabashi is of great interest.

**Key words:** Sultan Gabashi, composer, theater, music, folklore, opera.

Татар мәдәнияте тарихында онытылмаслык эз калдырган күренекле шәхесләр бар. Без татар композиторы, фольклорчы, музыка һәм җәмәгать эшлеклесе Солтан Хәсәнгата улы Габәшине зур хөрмәт белән искә алабыз. Үз заманы өчен башлап юл салучы, билгеле фигура булган бу талантлы шәхеснең язмышы гаҗәеп кызыклы. Музыкага көчле мәхәббәте, белемгә омтылышы, ташып торган энергиясе, үҗәтлеге һәм максатчанлыгы аркасында ул татар мәдәниятен чын мәгънәсендә алга этәрде. Музыкаль белеме дә булмаган мулла улы (фортепианода уйнарга өйрәтү буенча аерым дәресләр алудан тыш) беренче татар романслары, инструменталь пьесалар, мелодекламацияләр, музыкаль спектакльләр һәм хәтта опералар авторы була. Ул күпкырлы эшчәнлек алып бара: башкаручы, композитор һәм дирижер, фольклорчы, педагог һәм музыка коллективларын оештыручы буларак танылa. Көчле социаль тетрәнүләр чоры аның тормышына үз эзен салды, аны авырлыклар, казанышлар, шатлык-хәсрәтләр белән тутырды...

Солтан-Әхмәт Габәши 1891 елның 1 маенда Татарстанның Биектау районы Кече Сулабаш авылында дөньяга килә. Әтисе Хәсәнгата Мөхәммәд улы Габәши (1863–1936) үз заманының күренекле дин әһеле һәм җәмәгать эшлеклесе була. Солтан Габәши иң алдынгы татар мәдрәсәләрендә – башта Уфадагы «Госмания» һәм «Галия», аннан соң Казандагы «Мөхәммәдия»дә укый. Уфада Диния нәзарәтендә имтихан тапшырып, югары дин әһеле – имам-хатиб, мөдәррис

вазифасын башкару хокукы ала. Анда ул шулай ук реаль училищены да тәмамлый һәм бөтенләйгә Казанга күчеп кайта, 1915 елда Казан университетының юридик факультетына укырга керә, аның икенче курсында укыганда армиягә алына.

Солтан Габәшинең беренче иҗади уңышлары Уфа чоры белән бәйле. 1909 елда Уфадагы әдәби-музыкаль кичәләрдә катнашып, музыкаль эшчәнлеген башлап җибәрә һәм тиз арада танылган музыкант булып китә. Аның беренче әсәрләре – инструменталь пьесалары, романслары һәм җырлары Г. Тукай, С. Рәмиев шигырьләренә иҗат ителә. Соңрак драма спектакльләренә көйләр яза башлый. Аның үзе башкаруында яңгыраган көйләре моңлылыгы, ихласлыгы, тәэсирлелеге белән игътибарны җәлеп итә. Исеме афишалардан һәм газета битләреннән төшми. Яшь музыкантның иҗади мөмкинлекләре Казанда яңа көч ала. Ул Казанда татар зыялыларының мәдәни үзәге булган «Шәрык клубы»нда әдәби-музыкаль кичәләрдә даими катнаша.

1917 елда «Сәйяр» татар драма труппасы Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» драмасын сәхнәләштерә. Татар театры тарихында беренче булып махсус иҗат ителгән музыка белән башкарыла бу драма әсәре. Көйләрнең авторы Солтан Габәши була. Композитор бу тамашаны «музыкаль бизәлешле драма» дип атый. Һәм андагы музыкаль номерлар да авторның үзе җитәкчелегендәге оркестр тарафыннан башкарыла. Бу фактны барлык газеталар да диярлек күтәреп ала, «татар сәнгатендә яңа күренеш» дигән исем астындагы һәр язмада музыканың тамашачыларга гаять көчле йогынтысына басым ясала. Шуннан соң Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә», К. Рәхимнең «Бүз егет», Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт», К. Әмиринең «Йосыф белән Зөләйха», «Шаһ Габбас», «Ләйлә белән Мәҗнүн», Ә. Сәгыйдинең «Сак-Сок» әсәрләре дә музыка белән баетылып сәхнәләштерелә. Аларга да музыканы Солтан Габәши иҗат итә [Салитова, с. 195].

Композиторның иҗади эшчәнлеге 1920–1930 елларда – профессиональ музыкаль белем бирү формалашкан чорда аеруча активлаша. Солтан Габәши Казан Шәрык музыка техникумында төрле елларда мөдир урынбасары, Гыйльми совет секретаре, (татар телендә) музыкага өйрәтү мөгаллиме, татар хоры дирижеры булып эшли [Юнусова, с. 198]. С. Габәши анда беренче хор төркемен оештыра. Коллектив аның татар халык җырларыннан, биш һәм алты тавышка көйләп, хор өчен үзе эшкәрткән әсәрләрен һәм шәхси көйләрен башкара. Бу татар музыкаль культурасы өчен бөтенләй яңа һәм көтелмәгән күренеш була. Шәрык музыка техникумы хоры, соңрак Казандагы югары уку йортлары студентларын туплаган зур хор коллективы Солтан Габәши җитәкчелегендә концерт мәйданчыкларында әледән-әле чыгышлар ясап, тамашачыларның игътибарын җәлеп итә. Алар хакында матбугат битләрендә дә яктыртыла.

С. Габәши (Газиз Әлмөхәммәдев һәм Василий Виноградов белән автордашлыкта) – беренче татар опералары «Сания» (1925) һәм «Эшче»нең (1930) авторларыннан берсе. Милли опера иҗат итү ТАССР

тарихында мөһим вакыйгалардан санала, ул милли мәдәниятнең югары дәрәҗәгә ирешүе һәм шуның белән дөньякүләм сәнгать процессына кушылуы буларак бәяләнә [Исанбет, с. 63]. «Сания» операсы турында язмалар Берлинда чыга торган музыкаль атналыкта (№ 51 – 52, 1925) һәм Италиянең Көнчыгыш-Европа институты каршында нәшер ителүче журналда (30.10.1925) урын ала. Операның клавиры, авторлар һәм башкаручыларның фоторәсемнәре Франкфурт на Майнеда уздырылган халыкара күргәзмәдә демонстрацияләнә. «Эшче» операсы СССР халыкларының Бөтенсоюз олимпиадасында Мәскәүдә күрсәтелә. Беренче татар опералары сәхнәдә берничә сезон дәвамында уңыш яулый [Султанова, с. 142 – 149]. Беренче татар опералары, милли моңнар телен Европа опералары классик формасының синтезына нигезләп, опера спектакльләре иҗат итәргә мөмкин булуын раслый, һәм шуның белән татар композиторларына опералар иҗат итәргә юл ача. Солтан Габәши иҗаты татар музыка сәнгатен үстерүдә күпмедер дәрәҗәдә нигез булып тора һәм төп юнәлешне билгели (бигрәк тә халык музыка традицияләрен һәм Европа классик музыкасы чараларын синтезларга омтылуы аркасында) [Галимова, с. 148].

Солтан Габәши мөстәкыйль иҗади эшчәнлегендә гомере буе фольклорчы-музыкант булып кала. 1910 елда ук инде ул татар халык җырларын җыя, алар аның «Милли моңнар. Төрек-татар көйләре» җыентыгының нигезен тәшкил итәләр. Анда халык музыкасының дини жанрдагы сирәк очрый торган үрнәкләре – мөнәҗәтләр, бәетләр, ислам шигъри-музыкаль культурасы белән бәйле китаби моңнар тупланган. Г. Макаров билгеләп үткәнчә, «Ул заман Россиясендәге башка күп кенә халыклар фольклористикасының торышы белән чагыштырганда, Габәшинең музыкаль-этнографик эшләре шактый югары дәрәҗәдә тора. Ул халык традицияләрен, татар тарихын, классик ислам сәнгате нигезләрен яхшы белә, рус, гарәп, фарсы һәм төрек телле чыганаклар белән эшли ала» [Макаров, с. 142].

Солтан Габәши һәрвакыт татар сәнгатенә хас милли үзенчәлекләрне өстен куя. Аның бу сыйфаты иң элек үз иҗатында чагылыш таба. Үзенең чыгышларында һәм вакытлы матбугатта басылып чыккан хезмәтләрендә ул һәрвакыт гасырлар дәвамында тупланган музыкаль традицияләрне, фольклорның кыйммәтен һәм әһәмиятен, милли үзенчәлекләр белән Европа музыкасы жанрлары һәм формалары арасындагы тәңгәллекне, музыка белгечләре әзерләүне игътибар үзәгендә тота, докладлар белән чыгыш ясый, вакытлы матбугатта басыла.

Утызынчы елларда композиторны эзәрлекләү башлана. Аның сәбәбе – бер яктан, социаль чыгышы булса, икенче яктан – инкыйлабка кадәрге иҗатының милли юнәлеше, гасырлар дәвамында формалашкан музыкаль традицияләргә тугрылыгы. Солтан Габәшине пантюркизмда һәм панисламизмда, яңа пролетар мәдәнияткә каршы гамәлләрдә гаеплиләр, актив иҗтимагый һәм педагогик эшчәнлектән

читләштерәләр [Губайдуллина, с. 11]. Нәтиҗәдә, 1932 елда Солтан Габәши Газиз Әлмөхәммәдев чакыруы буенча Уфага килә.

Композитор тормышында Башкортстан чоры яңа иҗади күтәрелеш, педагогик һәм иҗади эшчәнлегенең активлыгы белән аерылып тора. Солтан Габәши Башкортстанның музыкаль культурасы үсешенә зур өлеш кертә. Ул берничә хор коллективы белән җитәкчелек итә, республиканың Милли-мәдәни фәнни-тикшеренү институтында фәнни эшләр алып бара һәм БАССР Халык Комиссариаты каршындагы сәнгать эшләре идарәсендә музыкаль фольклор кабинетын җитәкли; Уфа музыка көллиятендә укыта һәм, иң мөһиме, Башкортстан Композиторлар берлеген оештыруда катнаша. Композитор буларак та иҗади планнарын яңартып тора, музыка яза. 1935 елда композиторлар А. Ключарев һәм К. Рәхимов белән бергәләп, республиканың Ишембай районында фольклор экспедициясендә булалар, шуның нәтиҗәсе булып, С. Габәшинең күләмле җыентыгы («Сто башкирских песен») басылып чыга. 1937 елда музыка белгече Л. Лебединский белән башкорт җырлары язмалары өстендә эшли. 1940 елда Мәскәү композиторы Н. Чембержи белән «Сыңрау торна» балетына музыка язарга килешәләр, каралама рәвешендә генә булса да, Габәши аңа гаҗәеп матур яңгырашлы өзекләр дә теркәп куя. Композитор А. Эйхенвальд С. Габәшигә «Ашказар» операсы өстендә бергәләп эшләргә тәкъдим итә. 1930 еллар ахырында Казанда да, Уфада да «Сания» һәм «Эшче» операларын сәхнәгә чыгару мәсьәләсе күтәрелә. Шушы өмет белән канатланган С. Габәши үзенең автордашы композитор В. Виноградов белән операның яңа редакцияләре хакында хат алыша.

Әмма аның бу планнары тормышка ашмый кала. Бөек Ватан сугышы башланып китү һәм композиторны Уфа шәһәреннән сөреп җибәрү озак та тормый үзенең фаҗигалы нәтиҗәсенә китерә. 1941 елдан Солтан Габәши Борай районының Челкаково урта мәктәбендә укыта. Ә инде 1942 елның 8 гыйнварында авыр урман эшендә вакытта 51 нче яшендә вафат була. Шул ук авылда җирләнә дә.

Борай районы музыка мәктәбе һәм Казан шәһәренең Идел буе районындагы урам Солтан Габәши исемен йөртә. Челкаково мәктәбендә композиторның кечкенә генә музее оештырылган, анда аның шәхси әйберләре, фоторәсемнәре һәм документлары саклана. Туган мәдәниятенә фидакяр хезмәт куйган Солтан Габәшинең исеме, һичшиксез, беркайчан халык хәтереннән җуелмас, ә иҗаты җентекләп өйрәнелер.

**Әдәбият**

Габәши Солтан Хәсәнгата улы // Габдулла Тукай. Энциклопедия / гл. ред. З.З. Рамеев. Казань: Институт языка литературы и искусства им. Г. Ибрагимова, 2016. С. 165–166.

*Галимова Э.М.* С. Габәши музыкасында фольклор чагылышы // Фәнни Татарстан. № 4. 2016. Б. 149–153.

*Губайдуллина Г. Б.* Султан Габяши: художник и время // Султан Габяши. Материалы и исследования. Казань: Фикер, 2000. С. 9–26.

*Исанбет Ю.* От составителя // Газиз Альмухаметов и Султан Габаши в Казани. Материалы и документы. Уфа, 1995. С. 3–64.

*Макаров Г.М.* Султан Габяши и народная музыка // Султан Габяши. Материалы и исследования. Казань: Фикер, 2000. С. 140–157.

*Салитова Ф.Ш.* Музыкально-театральные произведения Султана Габяши // Султан Габяши. Материалы и исследования. Казань: Фикер, 2000. С. 193–202.

*Султанова Р. Р.* История татарского театра в плакатном искусстве. Казань, 2017. С. 142–149.

*Юнусова Г.Ф.* Первая татарская опера (к 80-летию со дня постановки оперы «Сания») // Эхо веков. 2005. № 1. С. 197–201.

***Салихова Айгөл Рөстәм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*